**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2017 елны Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать урыннары елы дип игълан итү турында**

Җәмәгатьчелекнең игътибарын экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, территорияләрне комплекслы үстерү һәм аларны төзекләндерү, халык өчен уңайлы шартлар булдыру мәсьәләләренә юнәлтү максатларында **карар бирәм**:

1. 2017 елны Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать урыннары елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай эчендә Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать урыннары елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай эчендә Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать урыннары елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Экология һәм җәмәгать урыннары елын уздыру эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать урыннары елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать урыннары елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 08 октябрь
№ ПУ-915